**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА ЯКУШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯКУШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

Якушкино
авылы

**30 октябрь 2019 ел** **№ 1**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Якушкино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының "Якушкино авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 11 ноябрендә 14.00 сәгать 00 минутка Якушкино авылы, Гагарин урамы, 2А йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Якушкино торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2019 елның 14 ноябрендә 14.00 сәгать 00 минутка Якушкино авылы, Гагарин урамы, 2А йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Якушкино торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлегенең Якушкино авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, 2020 елда һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару

буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү;

- зиратларны карап тоту;
- урамнарны яктырту һәм ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК».

6. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында һәм түбәндәге: Якушкино авылы, Мәктәп урамы, 1А , Якушкино авылы, Мәктәп урамы, 6 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Якушкино авыл җирлеге башлыгы Хәмидуллин Х.Х.